ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитеты**
423079 Яңа Ибрай авылы
Совет урамы, 5 йорт
тел. (факс) 884344- 4-27-27

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет Новоибрайкинского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**
423079 с.Новое Ибрайкино
улица Советская, д.5

КАРАР

№ 8 18.10.2021ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 27.12.2018 ел, 13 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакындагы 30.07.2021 ел, 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 27.12.2018 ел, 13 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.07.2021 № 6 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5. пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат системасы турында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2013 ел, № 443-ФЗ Федераль закон, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 19.11.2014ел, №1221 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә тигәл ярашытырып кулланыла.»;

1.2. 1.5. пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип димәк санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «төзелгән килешү нигезендә

муниципаль район башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы»сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.4. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе тарафыннан» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә; шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Х.Кәбиров